М.Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә ул Жизель (А.Аданның шул исемдәге әсәре буенча), Сванильда («Каппелия», Л.Делиб), Одетта-Одиллия, Аврора («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Раймонда (шул исемдәге әсәр буенча, А.Глазунов), Китри, Никия («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Тао Хао («Кызыл мәк», Р.Глиэр), Лауренсия (шул исемдәге әсәр, А.Крейн), Сөембикә (Фәрит Яруллинның «Шүрәле» исемле беренче татар балеты), Зарифа («Тау әкияте», А.Ключарёв), Зифа («Кисекбаш», Р.Гобәйдуллин), Раушан (З.Хәбибуллинның шул исемдәге әсәре) партияләрен һ.б. классик һәм милли балетларда әйдәп баручы рольләрне башкара.

1957 елда ул чит илләргә (Кытай, Бирма, Вьетнам) гастрольләр белән бара. Югары профессиональ хореография техникасы, ул иҗат иткән тирән эчтәлекле сәхнә образлары аны оста биюче буларак ача.

1968–1969 елларда Нинель Даутовна Ленинград хореография училищесында педагог, 1969–1973 елларда Татар опера һәм балет театрында баш балетмейстер булып эшли. Хореограф буларак аның куйган балет постановкалары: «Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл» (П.Чайковский), «Баядерка» (Л.Минкус), «Бакчасарай фонтаны» (Б.Асафьев), «Шүрәле» (Ф.Яруллин); С.Сәйдәшев, А.Ключарёв, Р.Яхин һ.б. музыкасына концерт номерлары.

Н.Д.Юлтыева озак еллар Н.К.Крупская исемендәге Ленинград мәдәният институтының Казан филиалында (соңрак – Казан дәүләт мәдәният институты) укыта. 1972 елдан хореография кафедрасы мөдире, 1985 елдан профессор була.

Нинель Даутовна чит илләрдә күп эшли: 1974–1977 елларда – Каһирә балет труппасының баш балетмейстеры һәм сәнгать җитәкчесе, 1981–1983 елларда – Каракас шәһәрендәге (Венесуэла) С.Боливар

исемендәге мәдәният үзәгендә Т.Кареньо исемендәге театрның балет труппасы балетмейстер-педагогы; 1988–1989 елларда Каһирә Югары балет институтының (Мисыр) сәнгать җитәкчесе.

1998 елдан 2014 елга кадәр Нинель Юлтыева Казан хореография училищесының сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкара.

Ул иң яхшы классик спектакльләрдә онытылмаслык образлар тудыра, чит ил, рус, милли классик балетларын искиткеч итеп сәхнәләштерә һәм бер төркем талантлы укучылар тәрбияли. Нинель Юлтыеваның исеме Россия балет сәнгате тарихына мәңгелеккә язылган.

Нинель Даутовнага Татарстан АССРның атказанган артисты (1953), РСФСРның (1957), Башкортстан Республикасының (1995) һәм Татарстан Республикасының (1996) халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул «Бию җаны» призына лаек була, «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышындагы фидакарь хезмәте өчен» медале белән бүләкләнә. Санкт-Петербургтагы Пётр исемендәге фән һәм сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы була.

Нинель Даутовна Юлтыева 2014 елның 23 ноябрендә Казанда вафат була. Арча зиратында җирләнә.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Юлтыева Нинель.** Адажио моей памяти. – Казань: ИД «АБВ», 2006. – 207 с.: фотоил.
Рец.: Батулла Р. Спасибо за книгу и за то, что Вы есть! // Респ. Татарстан. – 2007. – 13 марта.

**Юлтыева Н.** Мои первые роли в Казани: [отрывки из книги воспоминаний «Адажио моей памяти» ] // Казань. – 2023. – № 5. – С. 48–53.

**Юлтыева Н.** «Танцовщик – товар недолговечный и штучный» ] / беседу вела О.Иванычева // Казан. ведомости. – 1999. – 24 сент. – С. 13.

**Юлтыева Н.** Балет – он и в Африке балет / беседу вела О.Иванычева // Казан. ведомости. – 2003. – 22 апр. – С. 7.

**Юлтыева Н.** Счастливые заботы профессора / беседу вела Е.Демидова // Балет. – 2004. – № 2. – С. 57.

**Юлтыева Н.** Нинель Юлтыева: о времени и о себе / беседу записала А.Хазиева // Элита Татарстана. – 2008. – апр. – С. 84–85.

**Юлтыева Н.** «Балет – спорт һәм образ мәхәббәте» / әңгәмәне Л.Сөнгатуллина алып барды // Татарстан яшьләре. – 2001. – 17 март.

**Юлтыева Н.** Хәзер балетка искитмәле авыл балалары килә / [балерина белән әң-мә] // Ватаным Татарстан. – 2008. – 16 сент.

**Горшков В.Н.** Нинель Юлтыева: сотни жизней в одной. – Казань: изд-во Респуб. науч.-метод. центра народного творчества и КПР, 1996. – 24 с.

**Нинель Юлтыева** // Балет. – 2003. – № 1. – С. 8–9.

**Милицын Б.** Татарская Уланова: [воспоминание о Н.Юлтыевой] // Звезда Поволжья. – 2013. – 5–11 дек. – С. 4.

**Вяткина Н.** Нинель Юлтыева. Либретто для примы-балерины, балетмейстера, худрука // Казань. – 2021. – № 12. – С. 88 –93.

**Шакирзянов М.** Легенда о любви // Идель. – 1996. – № 11–12. – С. 51.

**Стрельникова О.** Ещё одно адажио // Респ. Татарстан. – 2006. – 9 февр. – С. 6, 15.

**Айрат Арсланов: истәлекләр** / төз. Р.Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 239 б. – Күренекле балерина, режиссёр һәм педагог. – Б. 194– 196.

**Горшков В.** Татар балеты аңа таҗ кидерде // Мәд. җомга. – 2001. – 16 февр. – Б. 17.

**Юнысова А.** Бердәнбер // Сөембикә. – 2006. – № 3. – Б. 11–13.

**Хәсәнова А.** Күңелләрдә татарлык булмаса… // Ватаным Татарстан. – 2011. – 25 февр. – Б. 5.

**Шакирҗан Л.** Сагышларны җиңгән балкышлы язмыш // Сәхнә. – 2011. – № 2. – Б. 6–9.

**Хәбибуллина Л.** Сабый чактан аны ачы язмыш сагалый // Шәһри Казан. – 2006. – 3 февр.

**Галиуллина М.** Сөембикә каурыйлары – яшь буынга мирас // Шәһри Казан. – 2001. – 2 февр.

**Юнысова А.** Юлтыева калфагы: шигырь // Сәхнә. – 2011. – № 2. – Тышл. 4-нче б.

## 15 февраля / 15 февраль



### Муса Джалиль
### Муса Җәлил

**1906–1944**

**120 лет со дня рождения**
**тууына 120 ел**

Поэт-герой Муса Джалиль (Муса Мустафович Залилов) родился 15 февраля 1906 года в деревне Мустафино Оренбургской губернии (ныне Шарлыкский район Оренбургской области). В шесть лет поступает в сельскую школу, а когда в 1913 года семья переезжает в Оренбург, учёбу продолжает в медресе «Хусаиния». В годы учёбы (1914–1917) близко знакомится с творчеством Г.Тукая, Дэрдменда, С.Рамиева и сам пробует сочинять стихи.

В октябре 1919 года в газете «Кызыл юлдуз» («Красная звезда») печатается его стихотворение «Счастье». Позже появляются и другие стихи.

В 1922 году М.Джалиль переезжает в Казань, работает в редакции газеты «Татарстан», а с 1923 года учится на Татрабфаке. На страницах газет и журналов печатаются его стихи и статьи, в 1925 году издаётся первый сборник стихов поэта «Барабыз» («Мы идём»).

В 1927 году М.Джалиль в Москве участвует в организации первых татарских детских журналов «Кечкенә иптәшләр» и «Октябрь баласы» и до конца 1932 года работает редактором этих журналов. Одновременно в 1927–1931 годах учится в Московском университете.

В 1933–1934 годах М.Джалиль возглавляет отдел литературы и искусства московской газеты «Коммунист». В 1934 году выходит ещё один сборник стихов поэта и первое издание избранных стихов на русском языке.

В 1935 году при Московской консерватории организуется Татарская оперная студия, куда Джалиля приглашают на должность заведующего литературной частью. Он собирает вокруг себя поэтов, композиторов, организует переводы на татарский язык классических оперных либретто, оказывает творческую помощь в создании первых татарских опер.

В 1938 году, после открытия в Казани театра оперы и балета, вместе с оперной труппой сюда переезжает и Джалиль.

Общение с композиторами, тесная связь с миром музыки вдохновляют поэта на создание новых произведений. Он – автор текстов популярных песен, романсов. В его творчестве появляется новый жанр – жанр драматической поэмы. На основе его поэм «Алтынчеч» и «Ильдар» композитор Н.Жиганов создаёт свои знаменитые оперы. В 1948 году опере «Алтынчеч» присуждается Государственная премия СССР.

В 1939–1941 годах М.Джалиль назначается ответственным секретарем правления Союза писателей Татарстана.

В июле 1941 года М.Джалиля призывают в армию. Он назначается военным корреспондентом газеты «Отвага» Северо-Западного фронта. В июне 1942 года в боях на Волховском направлении их часть попадает в окружение. Тяжело раненый М.Джалиль попадает в плен, проходит через фашистские лагеря. Находясь в немецком плену, принимает активное участие в деятельности подпольной группы татарских военнопленных.

25 августа 1944 года М.Джалиль вместе с десятью товарищами по подполью был казнён в фашистской тюрьме Плетцензее.

2 февраля 1956 года Указом Президиума Верховного Совета СССР за героизм в годы Великой Отечественной войны М.Джалилю присвоено звание Героя Советского Союза.

За поэтическое творчество – цикл «Моабитская тетрадь» – поэт в 1957 году был удостоен Ленинской премии.

«Моабитская тетрадь» – вершина поэзии Мусы Джалиля. Цикл стихов переиздавался десятки раз на татарском и русском языках, переведён на многие другие языки.

В 1968 году была учреждена Премия комсомола Татарии им. М.Джалиля (с 1997 года – Республиканская премия им. М.Джалиля), в 1966 году установлен памятник поэту (скульптор В.Е.Цигаль, архитектор Л.Г.Голубовский), в 1970 году открыт мемориальный музей М.Джалиля в городе Мензелинске, в 1983 году – музей-квартира в Казани.

**Г**ерой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә туа. Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, 1913 елда гаилә Оренбургка күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914–1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С.Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша, үзе дә шигырьләр яза башлый.

1919 елның октябрендә «Кызыл йолдыз» газетасында Мусаның «Бәхет» исемле шигыре басыла. Шуннан соң аның башка шигырьләре дә матбугат битләрендә күренә.

1922 елда М.Җәлил Казанга килә, «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елдан Татрабфакта укый башлый. Газета-журналларда аның бер-бер артлы шигырьләре, мәкаләләре басыла, 1925 елда «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.

1927 елда М.Җәлил Мәскәүдә беренче татар балалар журналларын («Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы») оештыруда актив катнаша һәм 1932 елның ахырына кадәр шул журналларның җаваплы редакторы булып эшли. Бер үк вакытта ул, 1927–1931 елларда Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать факультетында укып, югары белем ала.

1933–1934 елларда М.Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. 1934 елда шагыйрьнең «Орденлы миллионнар» шигырьләр җыентыгы һәм шул ук елны «Стихи Мусы Джалиля» исеме белән беренче мәртәбә рус телендә сайланма шигырьләре дә чыга.

1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар опера студиясе оештырылгач, М.Җәлил шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакырыла. Ул үз тирәсенә шагыйрьләрне, композиторларны туплый, либреттолар язарга булыша, беренче татар операларының тууына турыдан-туры иҗади ярдәмен күрсәтә. 1938 елда Казанга кай-

тып, М.Җәлил опера театрының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшли.

Композиторлар белән аралашу, музыка дөньясы белән тыгыз бәйләнеш тоту М.Җәлил иҗатында яңа үзгәрешләр туууга сәбәп була. Аның «Сагыну», «Җир җиләгем», «Җырым булсын бүләгем», «Карашларың» кебек шигырьләре, композиторлар тарафыннан музыкага салынып, халыкның яраткан җырларына әвереләләр. Әдипнең иҗатында яңа жанр – драматик поэма жанры да барлыкка килә; «Алтынчәч», «Илдар» драматик поэмалары нигезендә композитор Н.Җиһанов үзенең атаклы операларын иҗат итә. 1948 елда «Алтынчәч» операсына СССР Дәүләт премиясе бирелә.

1939–1941 елларда М.Җәлил Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре вазифасын башкара.

1941 елның июль аенда М.Җәлил армиягә алына. Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган «Отвага» газетасының хәрби корреспонденты итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, алар часте чолганышта калып, М.Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә. Шул көннән патриот шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы газаплы һәм героик тормыш этабы башлана.

М.Җәлил, концлагерьда яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы көрәш алып бара.

1944 елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Җәлил һәм аның 10 көрәштәшенең гомере өзелә.

1956 елның 2 февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән М.Җәлилгә Ватан сугышы чорында күрсәткән батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты – бөтен дөньяга мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә лаек була.

«Моабит дәфтәрләре» – Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләре шагыйрьне әдәбиятның бөтендөнья орбитасына алып чыга.

1968 елда Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе оештырыла (1997 елдан – М.Җәлил исемендәге Республика премиясе), 1966 елда Казанда һәйкәле куела (скульпторы В.Е.Цигаль, архитекторы Л.Г.Голубовский), 1970 елда Минзәләдә мемориаль музей, 1983 елда Казанда музей-квартирасы ачыла.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Муса Җәлил: библиогр. күрсәткеч. 1919–1973 = Муса Джалиль: библиогр. указ. 1919–1973** /[төз. Н.Әхмәтҗанова һ.б.]. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. – 222 б. – Текст татар һәм рус телләрендә.

**Муса Җәлил: әдәбият күрсәткече. 1974–1984 = Муса Джалиль: указатель литературы. 1974–1984** / [төз. Н.Әхмәтҗанова һ.б.]. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1987. – 127 б. – Текст татар һәм рус телләрендә.

**Джалиль М.** Сквозь бури: избранные стихи и поэмы /[пер. татар]. – М.: Сов. Россия, 1986. – 398 с.

**Джалиль М.** Стихотворения /[пер. с татар.; сост. Ч.Залилова]. – М.: Худож. лит., 1986. –287 с.

**Джалиль М.** Утренняя звезда: песни на стихи Мусы Джалиля. – 2-е изд., доп. – М.: Музыка, 1986. – 48 с.

**Джалиль М.** Костёр над обрывом: стихи и поэмы. Письма. Из воспоминаний о поэте /[пер. с татар.]. – М.: Правда, 1987. – 567 с.

**Джалиль М.** Пылай, моя песня!: стихи и поэма /[пер. с татар.]. – М.: Сов. Россия, 1989. – 401 с.: с портр.

**Джалиль М.** Избранное / [пер. с татар]. – М.: Худож. лит., 1990. – 462 с.

**Джалиль М.** Избранное: стихи из Моабитской тетради на татар., рус. и казах. яз. / [автор проекта, сост. Р. Дусумов]; пер. на казах. язык М.Абдрахманова. – Доп. изд. – Кокшетау: Мир печати, 2019. – 95 с.: ил., портр. – Текст парал.: рус., татар., казах.

**Джалиль М.** Избранное: стихотворения / рук. проекта, сост. Л.Шаех; пер. с татар. М. Фофановой [и др.]. – 2-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2023. – 303 с.: ил., портр. – (Классическая татарская поэзия).

**Джалиль М.** Моабитские тетради = Моабит дәфтәрләре = Moabiter hefte = Moabit notebooks / автор предисловия И.Храмов; перевод предисловия на татар. язык А.Абдулхаликовой, на нем. язык И.Храмова, на англ. язык Р.Галимова; пер. стихов: Р.Галимов, А.Абдулхаликова, И.Френкель [и др.]. – Оренбург: Оренбург. кн. изд-во, 2024. – 383 с.: ил. – Парал. текст на рус., татар. яз., также стихи в пер. на англ. и нем. яз.

**Җәлил М.** Әсәрләр: биш томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

Т.1: шигырьләр (1921–1941) / [кереш сүз авт. Р.Ә.Мостафин]. – 2006. – 431 б.

Т.2: шигырьләр (1941–1944); либреттолар; шагыйрь архивыннан. – 2006. – 382 б.

Т.3: шигырьләр, поэмалар, тәрҗемәләр. – 2006. – 368 б.

Т.4: әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм биографик материаллар. – 2006. – 318 б.

Т. 5: сәнгать турында мәкаләләр һәм хатлар. – 2006. – 319 б.

**Җәлил М.** Әсәрләр / [кереш сүз язучы Т.Галиуллин]. – Казан: Мәгариф, 2004. – 271 б.

**Җәлил М.** Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр / [төз. Ф.Г.Галимуллин]. – Казан: ТаРИХ, 2004. – 575 б. – (Мәктәп к-ханәсе; XXXI).

**Җәлил М.** Кызыл ромашка: балалар өчен шигырьләр, җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 143 б.: рәс.

**Җәлил М.М.** Сайланма әсәрләр: шигырьләр / [төз. һәм кереш сүз авт. Л.Шәех] = Джалиль М.М. Избранное: стихотворения / [сост. и авт. предисл. Л.Шаех]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 423 с.

**Җәлил М.** Сайланма әсәрләр / проект җит. һәм кит. төз. Л.Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – 303 б.: портр. б-н. – (Классик татар шигърияте).

**Җәлил М.** Моабит дәфтәрләре = Моабитские тетради: факсимиль басма / кереш сүз язучы Р.Ә.Мостафин; төз. Р.Ф.Рахмани; текст. гарәп һ. латин графикасыннан күчерүче И.Мөстәкыймов. – 3 факс. басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2025. – 214 б.: факс., портр. – Текст парал татар, рус тел. – М. Җәлил тур. алман, инглиз тел.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. справочник. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 510 с. – Муса Джалиль. – С. 161-168.

**Бикмухаметов Р.** Муса Джалиль: Личность. Творчество. Жизнь. – М.: Худож. лит., 1989. – 286 с.

**Мустафин Р.** Муса Джалиль: жизнь и творчество (довоенный период). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 383 с.

**Мустафин Р.А.** По следам оборванной песни. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2021. – 406 с.

**Муса Джалиль и патриотические традиции в советской литературе: материалы Всесоюз. науч. конф., посвящ. 80-летию поэта-героя.** – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989.– 240 с.

**Ахтамзян А.А.** Муса Джалиль и его соратники в сопротивлении фашизму: из «Моабитской тетради». – 2-е изд., доп. – Казань: ПИК «Идел-Пресс». – [2015]. – 206 с. + 8 л. фот.: портр.

**Муса Джалиль: жизнь и творчество через призму ценностей XXI века: материалы межд. науч. конф. «Джалиловские чтения» (15–16 февраля 2016 года).** – Казань: Фо-

лиант, 2016. – 447 с. – Библиогр. в конце ст. – Тит. л. и текст рус., татар.

**Курбан Р.** Отчизна: роман / [пер. с татар. М.Сафин]. – Казань: ТипоГрафф, 2019. – 247 с.

**Забиров И.** Джалиль и джалильцы: докум. очерки и этюды. – 2-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 143 с.

**Колотило А.** Политрук из «Долины смерти» // Красная звезда. – 2018. – 5 окт. – С. 10.

**Мирхайдаров Р.** Поэт… Воин! … Муса Джалиль… : [воспоминания о Мусе Джалиле] // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2022. – № 11. – С. 13.

**Харис Р.** Сто четырнадцать шагов к бессмертию // Лит. газ. – 2019. – 19–25 июня. – С. 14.

**Шакиров А.** 56 дней без войны: [М.Джалиль учился на военно-политических курсах в Мензелинске] // Татарстан. – 2024. – № 5. – С. 78–81.

**«Мы поём…» = «Без җырлыйбыз…»: хоровая музыка композиторов Татарстана на стихи Мусы Джалиля** / [сост. и ред. А.И.Запарова]. – Казань: [Казанская государственная консерватория], 2014. – 78 с.: ноты.

**Фаттахова Н.** Музей-квартира Мусы Джалиля: [буклет]. – Казань-Kazan-Казан, 2002. – 16 с.: фот.; Казань. – 2002. – № 9. – С. 17–32.

**Муса Җәлил – документларда: фәнни-популяр җыентык** / төз. Р.Исламов. – Казан: Җыен, 2021. – 831 б. + [32] б. фоторәс.: рәс. – («Шәхесләребез» сериясе = Сер. «Знаменитые личности»).

**Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек.** 2 томда. Т.1 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Муса Җәлил. – Б. 511–515.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Муса Җәлил. – Б. 615–621.

**Мостафин Р., Йосыпова Н.** Муса Җәлил // Татар әдәбияты тарихы. 8 томда. Т. 5: 1917–1956 еллар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – Б. 243–264.

**Юзиев Н.** Муса Җәлил // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 65–87.

**Бәдигый Х.** Муса Җәлил поэтикасы: әдәби-гыйльми, фәнни-публицистик хезмәтләр / [кереш сүз авт. Т.Галиуллин]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 446 б.: портр. б-н.

**Мостафин Р.** Җәлилчеләр: очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 263 б.

**Мусабәкова Р.** Муса Җәлил (1906–1944) // Кырык татар = Сорок татар = The Forty Tatars. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 91–101. – Текст татар., рус., ингл. тел.

**Юзиев Н.** Әдәбият чыганаклары белеме: (әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре). – Казан: Фикер, 1998. – 175 б. – Муса Җәлил мирасын туплау. – Б. 120–127.

**Давыдов Ә.** Муса абый: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 112 б.

**Басыйров Х., Басыйров А.** Ватанга тугры калдылар: док. повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 510 б.: портр., фоторәс.

**Корбанов Т.** Кызыл чәчәкләр: истә калганнар: док. повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 128 б.

**Корбан Р.** Ватан: роман. – Казан: «ТипоГрафф», 2018. – 291 б.: рәс.

**Галимуллин Ф.** Батырларыбызның да батыры // Мәгариф. – 2021. – № 2. – Б. 11–15.

**Хәмидуллин Л.** Ак төннәр хәтере: әдәби очерк, эссе, хатирәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 224 б. – Муса иҗатының та-

янычлары; Уралда онытмыйлар Җәлилне; Бакыр һәйкәл. – Б. 120–131.

**Мостафин Р.** Муса Җәлил: «Син ышанма бәгърем...»:[«Моабит дәфтәрләре»ндә патриотизм темасы] // Мәгариф. – 2005. – № 2. – Б. 6–7.

**Харис Р.** Хәбәр: шигырьләр, җырлар, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 367 б. – Җәлилчеләр (поэма). – Б. 311–320.

**Җырым белән җиңдем дошманны: татар халкының мәшһүр улы, каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулуга багышланган методик-библиогр. ярдәмлек** / төз Р.Р.Гаязова, мөх-р И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2021. – 43 б.

## 23 февраля / 23 февраль



### Гильм Хайревич Камай
### Гыйлем Хәйри улы Камай

**1901–1970**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Видный химик, учёный с мировым именем Гильм Хайревич Камай (Гильметдин Хайретдинович Камалиев) родился 23 февраля 1901 года в городе Тетюши Казанской губернии (ныне Республика Татарстан) в семье волжского грузчика. Оставшись без отца в 9 лет, Г.Камаю пришлось начать трудовую жизнь: работать погонщиком лошадей, носильщиком ручной клади, подручным у ломового извозчика и т.д. В 1916–1920 годах он учится в Татарской учительской школе в Казани, а летом трудится рабочим на пристанях.

В 1920 году Г.Камая призывают в Красную Армию, он участвует в боях против белогвардейских войск.

После демобилизации, в 1922 году Г.Х.Камай поступает и в 1926 году оканчивает химическое отделение физико-математического факультета Томского университета, а затем переезжает в Казань, где обучается в аспирантуре Казанского университета.

По окончании аспирантуры и защиты диссертации Г.Камая избирают заместителем декана физико-математического факультета КГУ, а в 1929 году его направляют за границу в Германию, в Тюбингенский университет, где он показывает себя как хорошо подготовленный учёный-химик.

В Казань Гильм Хайревич вернулся вполне сложившимся научным работником. 11 марта 1941 года он блестяще защищает докторскую диссертацию.

Вся жизнь Г.Х.Камая посвящается служению науке, подготовке кадров химиков и активной общественной деятельности.

Г.Х.Камай прошёл большой научный путь. Начав свои исследования в области химии органических соединений фосфора под руководством А.Е.Арбузова, он вскоре основал и развил оригинальное научное направление в области химии мышьякорганических соединений. Гильм Хайревич многие годы успешно руководил коллективом учёных, выполнявших важные правительственные задания.

Во время Великой Отечественной войны Г.Х. Камай принимает самое активное участие во многих работах, связанных с удовлетворением потребностей фронта и тыла. Его научные труды в области нитросоединений (взрывчатых веществ) имели большое значение для оборонной промышленности. Своими исследованиями он внёс значитель-

ный вклад в дело победы над врагом в Великой Отечественной войне.

Г.Х.Камай – автор около 400 научных работ и 50-ти авторских свидетельств. Им подготовлены 7 докторов, 40 кандидатов наук и сотни инженеров-химиков для народного хозяйства.

Г.Х.Камай был не только крупным учёным, но и выдающимся организатором науки и общественным деятелем. В 1931 году он первым из татар стал профессором-химиком Казанского университета. С 1935 по 1937 год – ректор Казанского университета, в 1930–1931 и в 1944–1945 годах – заместитель директора КХТИ, с 1945 по 1952 год – учёный секретарь Казанского филиала Академии наук СССР. Он – страстный пропагандист научных знаний, заботливый воспитатель молодёжи.

Г.Х.Камаю присуждена Государственная премия СССР; награждён двумя орденами Ленина, двумя орденами Трудового Красного Знамени. Он – заслуженный деятель науки и техники ТАССР и РСФСР.

Г.Х.Камай умер 17 марта 1970 года в Казани. Похоронен на Новотатарском кладбище.

Имя Г.Х.Камая увековечено. В 1994 году Академия наук РТ учредила Премию им. Г.Х.Камая за лучшие работы в области химии и химических технологий. Его имя носит одна из улиц Казани. В 1978 году на главном здании Казанского химико-технологического института (ныне Казанский национальный исследовательский технологический университет) установлена памятная доска в его честь.

Күренекле химик, исеме бөтен дөньяга танылган татар галиме Гыйлем Хәйри улы Камай (Гыйльметдин Хәйретдин улы Камалиев) 1901 елның 23 февралендә Казан губернасының (хәзер Татарстан Республикасының) Тәтеш шәһәрендә йөк төяүче гаиләсендә туа. 9 яшендә әтисез калган Гыйлемгә хезмәт юлын башларга – төрле авыр эшләр башкарырга туры килә.

1916–1920 елларда ул Казанда Татар укытучылар мәктәбендә укый, җәй көннәре пристаньдә эшли. 1920 елда Г.Камай Кызыл Армиягә алына, акгвардия гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша.

Демобилизациядән соң, 1922 елда Г.Х. Камай Томск университеты физика-математика факультетының химия бүлегенә укырга керә һәм 1926 елда аны тәмамлый, ә аннары Казанга күчеп килә һәм Казан университетының аспирантурасында укый.

Аспирантураны тәмамлагач һәм диссертация яклагач, Г.Камайны КДУның физика-математика факультеты деканы урынбасары итеп сайлыйлар, ә 1929 елда аны чит илгә – Германиягә, Тюбинген университетына җибәрәләр, анда ул үзен яхшы әзерләнгән галим-химик буларак күрсәтә.

Казанга Г.Камай чын мәгънәсендәге фән эшлеклесе булып кайта. 1941 елның 11 мартында ул докторлык диссертациясен бик уңышлы яклый.

Г.Х.Камайның бөтен тормышы фәнгә хезмәт итүгә, химия кадрлары әзерләүгә һәм актив җәмәгать эшенә багышлана.

Г.Х.Камай зур фән юлы үтә. Профессор А.Е.Арбузов җитәкчелегендә фосфорның органик кушылмалары химиясе өлкәсендә тикшеренүләрдән башлап, ул тиз вакыт эчендә мышьяклы органик кушылмалар өлкәсендә оригинал фәнни юнәлешкә нигез сала һәм аны үстерә. Г.Х.Камай хөкүмәтнең мөһим заданиеләрен үтәүче галимнәр коллективына күп еллар буе уңышлы җитәкчелек итә.

Бөек Ватан сугышы вакытында Г.Х.Камай фронт һәм тыл ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә бәйле күп кенә эшләрдә актив катнаша. Аның нитрокушылмалар (шартлаткыч матдәләр) өлкәсендәге фәнни хезмәтләре оборона промышленносте өчен зур әһәмияткә ия була. Ул үзенең тикшеренүләре белән Бөек Ватан сугышында дошманны җиңүгә шактый зур өлеш кертә.

Г.Х.Камай – 400 гә якын фәнни хезмәтнең һәм иллеләп ачыш таныклыкларының авторы. Ул 7 доктор, 40 фән кандидаты һәм йөзләрчә инженер-химиклар хәзерли.

Г.Х.Камайны, күренекле галим һәм педагог булу белән бергә, фәндә күренекле оештыручы һәм республикада күренекле җәмәгать эшлеклесе дә итеп таныйлар.

1931 елда ул, татарлардан беренче булып, Казан дәүләт университетының химия профессоры исемен ала. 1935–1937 елларда – Казан университеты ректоры, 1930–1931 һәм 1944–1945 елларда Казан химия-технология институты директоры урынбасары, 1945–1952 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында гыйльми сәркятиб вазифаларында эшли. Г.Х.Камай – фәнни белемнәрне ялкынлы пропагандалаучы, яшьләрне яратып тәрбияләүче.

Галимгә СССР Дәүләт премиясе бирелә, ике тапкыр Ленин ордены, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Ул – ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе.

Г.Х.Камай 1970 елның 17 мартында Казанда вафат була. Яңа Татар зиратында җирләнә.

Г.Х.Камайның исеме мәңгеләштерелгән. 1994 елда ТР Фәннәр Академиясе химия һәм химик технологияләр өлкәсендәге иң яхшы эшләр өчен Г.Х.Камай исемендәге премия булдыра. Казан урамнарының берсе аның исемен йөртә. 1978 елда Казан химия-технология институтының (хәзерге Казан милли тикшеренү технология университеты) төп бинасында аның хөрмәтенә истәлек тактасы урнаштырыла.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:


**Камай Г.Х.** Академик А.Е.Арбузов. – Казань: Татгосиздат, 1952. – 32 с.: ил.

**Камай Г.Х.** Мечте навстречу / [лит. запись В.В.Пошатаева]. – М.: Сов. Россия, 1970. – 128 с.: 8 л. ил.

**Камай Г.Х.** Бөек рус галиме А.М.Бутлеров. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 16 б.: портр.

**Камай Г.** Казан химиклары / тулыл. 2 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 55 б.: рәс., портр. – Исем. күрс.: Б. 53–55.

**Камай Г.** Тормышка ашкан хыял / тәрҗ. Р. Сабиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 144 с.: рәс., портр.

**Камай Г.** Химикка Гомер кирәкме? // Безнең мирас. – 2022. – № 1. – Б. 18–23.

**Камай Г.** Синтетик материалларга юл бирик // Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 169–171.

**Гильм Хайревич Камай: библиографическая справка. 1901–1970** / Казанский государственный технологический университет. – Казань: Издательство КГУ, 2001. – 51 с.: фото.

**Профессор Гильм Хайревич Камай: биобиблиогр. (1928–1972 гг.)** / сост. Р.А.Галявин. – Казань: КХТИ, 1973. – 84 с.

**Гильм Камай** / сост. А.С.Лозовой, Н.Н.Амирханова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 120 с.: 8 л. ил.

**Валеева Н.Ш., Вьюгина С.В.** Научно-педагогический потенциал химической школы Г.Х.Камая. – Казань: Казанский государственный технологический университет, 2005. – 135 с.

**Мифтахова Н.Ш.** Становление химического образования татарского народа. – Казань: Фән, 2004. – 503 с. – Камалиев Гильметдин Хайретдинович (Гильм Хайревич Камай). – С. 326–328.

**Мифтахова Н.Ш.** Химия в просвещении татарского народа. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2005. – 368 с.: ил., портр. – Камалиев Гильметдин Хайретдинович (Гильм Хайревич Камай). – С. 254–256.

**Султанбеков Б.** Трагические и триумфальные страницы жизни: [о репрессии учёного-химика Г.Х.Камая в 1937 г. («Дело химиков»)] // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2007. – № 2. – С. 55–59.

**Татарские учёные** / сост. и отв. ред. И.Р.Утямышев. – М.: У Никитских ворот, 2022. – 375 с.: ил., портр. – Камай Гильм Хайревич. – С. 177–178.

**Мельникова Г.Ф.** Г.Х.Камай – первый татарский учёный-химик // TATARICA. – 2016. – № 1 (6). – С. 214–218.

**Гамаюрова В.** Первый татарский профессор Гильм Камай // Казань. – 2001. – № 12. – С. 26.

**Садриева Г.К.** Г.Х.Камай: педагог, учёный, гражданин // Химия в школе – 2019. – № 9. – С. 68–73.

**Ямбушев Ф.** Преемственность научно-педагогического наследия Гильма Камая // Мәгариф. – 2021. – № 3. – С. 67–70.

**Хисамиев Г., Харрасова Ф.** Беренче татар профессоры // Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 165–169; Мәйдан. – 2024. – № 4. – Б. 87–91.

**Мусабәкова Р.** Гыйлем Камай (1901–1970) // Кырык татар = Сорок татар = The Forty Tatars. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 144–153. – Текст татар., рус., ингл. тел.

**Булатов Н.** Идел бөркете: [ галим Г.Камайның тууына 100 ел] // Ватаным Татарстан. – 2001. – 7 март.

**Хисамиев Г.** Гыйлем Камай һәм аның иҗаты // Фән һәм тел. – 1999. – № 1. – Б. 23–25.

**Гыйлем Камай** // Мәгариф. – 2006. – № 8. – Б. 73.

**Фәйзрахманов Ә.** Гыйлем Камай // Татарстан яшьләре. – 2021. – 8 апрель. – Б. 6.

## 25 марта / 25 март



### Гульсум Камская
### Гөлсем Камская

**1901–1975**

**125 лет со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Талантливая актриса Гульсум Сайфулловна Камская (Ильясова) родилась 25 марта 1901 года в городе Казани. Сценическую деятельность начала в Татарском театре имени Красного Октября (ныне Татарский Государственный академический театр им. Г.Камала) в 1919 году. В 1922–1926 годах работала в Астраханском татарском драматическом театре, в 1927–1933 годах – в Московском центральном татарском рабочем театре, а с 1933 года являлась актрисой Татарского академического театра в Казани, на сцене которого расцвёл её многогранный талант.

Г.Камская сыграла свыше 100 ролей, многие из которых вошли в историю татарского сценического искусства. За полувековой период сценической деятельности ею созданы десятки разнохарактерных образов в спектаклях по произведениям татарской, русской и мировой драматургии. Ее игра всегда была от-

мечена глубиной мысли, тонким психологизмом, ярким национальным своеобразием.

Выдающийся мастер перевоплощения, Г.Камская достигла предельной убедительности в передаче характеров скупыми и точными деталями, жестами, манерой речи.

Исполнение наиболее значительных ролей как Нагима («Банкрот» Г.Камала), Галчиха, Кукушкина («Без вины виноватые», «Доходное место» А.Островского), Магинур («Минникамал» М.Амира), Блюм («Жизнь начинается снова» В.Собко), Гульниса («Тревожные дни» Т.Гиззата), Сахиля («Ходжа Насретдин» Н.Исанбета), Сабира («Судьба татарской женщины» Г.Ибрагимова) и др. стало значительным вкладом в развитие татарского театрального искусства. Эти роли принесли актрисе широкую известность.

Г.Камская принимала активное участие в общественной жизни театра, делилась своим богатым творческим опытом с молодыми артистами.

За большие заслуги в развитии театрального искусства Г.С.Камской были присвоены почётные звания народной артистки ТАССР (1951), заслуженной артистки РСФСР (1957).

Г.С.Камская умерла 8 декабря 1975 года.

Талантлы актриса Гөлсем Сәйфулла кызы Камская (Ильясова) 1901 елның 25 мартында Казан шәһәрендә туа. Ул сәхнә эшчәнлеген 1919 елда Кызыл Октябрь исемендәге Татар театрында (хәзер Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры) башлап җибәрә. 1922–1926 елларда Әстерхан татар драма, 1927–1933 елларда Мәскәү үзәк татар эшче театрларында эшли, 1933 елдан ул – Татар дәүләт академия театры актрисасы. Шушы театр сәхнәсендә аның күпкырлы таланты чәчәк ата.

Г.Камская 100 дән артык роль башкара, аларның күбесе татар сәхнә сәнгате тарихына кереп кала. Ярты гасырлык сәхнә эшчәнлеге чорында ул татар, рус һәм дөнья драматургиясе әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләрдә төрле характердагы дистәләрчә образлар иҗат итә.

Яңача гәүдәләндерү остасы буларак, Г.Камская төгәл детальләр, хәрәкәтләр, башкару рәвеше, сөйләү манерасы ярдәмендә ышандырырлык характерлар иҗат итә. Аның героиняларының сәхнәдәге тормышы һәрвакыт тирән фикерләр, нечкә психологизм, милли үзенчәлекләр хас булу белән аерылып тора.

Аеруча игътибарга лаек – Нагыймә («Банкрот», Г.Камал), Галчиха, Кукушкина («Гаепсездән гаеплеләр», «Төшемле урын», А.Островский), Маһинур («Миңлекамал» М.Әмир), Блюм («Тормыш яңадан башлана», В.Собко), Гөлниса («Шомлы көннәр, Т.Гыйззәт), Сәхилә («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Сабира («Татар хатыныниләр күрми», Г.Ибраһимов) һәм башка ул уйнаган рольләр татар театр сәнгатен үстерүдә зур өлеш була, актрисага шөһрәт китерә.

Г.Камская театрның җәмәгать эшләрендә актив катнаша, яшь артистлар белән үзенең бай иҗат тәҗрибәсен уртаклаша.

Театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Гөлсем Камскаяга ТАССРның халык (1951) һәм РСФСРның атказанган артисткасы (1957) дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Г.С.Камская 1975 елның 8 декабрендә вафат була.

### Советуем прочитать:
### Укырга тәкъдим итәбез:

**Ильясов А.** Святая косточка: [воспоминания сына о матери] // Казань. – 1995. – № 1–2.

– С. 5–20, 130–151; № 3–4. – С. 33–49; 1996. – № 1–2. – С. 144–164.

**Ильясов А.** Всё, что было отнято, она отдала театру // Респ. Татарстан. – 2001. – 24 марта. – С. 5.

**Зиганшина А.** Судьба была к Дикой Баре неласкова // Вечерняя Казань (Конец недели). – 2004. – 24 марта.

**Илялова И.И.** Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г. Камала: биографик белешмәлек. – Тулыл. 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 333 б.: портр. – Камская (Ильясова) Гөлсем Сәйфулла кызы. – Б. 59–60. – Текст парал. татар., рус.тел.

**Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел: ике томда** = Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет: в двух томах: альбом. Т. 2. – Казан: Заман: Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б.: портр., фоторәс. б-н. – Камская (Ильясова) Гөлсем Сәйфулла кызы. – Б. 86. – Текст парал. татар, рус тел.

**Арсланов Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан, Заман, 2014. – 584 б. – Камская (Ильясова) Гөлсем Сәйфулла кызы. – Б. 303–304.

**Ильясов Ә.** Изге сөяк: әниемнең якты истәлегенә / Ә.Гаффар тәрж. // Казан. – 1995. – № 1–2. – Б. 4–20, 105–120; № 3–4. – Б. 33–46; 1996. – № 3–4. – Б. 149–168.

**Ильясов Ә.** Гөлсем Камская театрга йөрәк кушуы буенча килгән // Шәһри Казан. – 2001. – 23 март.

**Җиһаншина Р.А.** Күңелем түреннән: истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 96 б. – «Алай кочаклама, акыллым!.. ». – Б. 14–18.

**Шакиров Ә.** Шәхесләр, язмышлар... // Казан утлары. – 2016. – № 3. – Б. 154–157.

**Галиуллина М.** Чәчкәләрсез язмыш // Мәд. җомга. – 2020. – 14 авг. – Б. 12–13.

**Хәйретдинова Р.** Сәхнәдәшем күз алдыннан китми // Шәһри Казан. – 2005. – 25 март.

**Гыймранова Д.** Төп рольләрдә уйнамаган актриса // Мәд. җомга. – 2001. – 30 март. – Б. 17.

## 26 апреля / 26 апрель



### Габдулла Тукай

**1886–1913**

**140 лет со дня рождения**
**тууына 140 ел**

Великий поэт татарского народа, литературный критик, публицист Габдулла Тукай (Габдулла Мухамметгарифович Тукаев) родился 26 апреля 1886 года в деревне Кушлавыч Казанской губернии (ныне Арский район Республики Татарстан) в семье муллы. С малых лет Габдулла остаётся круглым сиротой и испытывает тяготы сиротства.

Азы грамоты Габдулла постигает в деревне Кырлай; великолепная природа деревни и народные традиции, обычаи дают будущему поэту духовную пищу на всю жизнь.

В 1895 году Габдуллу отправляют к родственникам в город Уральск. Здесь он учится в медресе «Мутыйгия», одновременно посещает трехгодичный русский класс. Отлично усвоивший арабский, персидский и турецкий языки, он вскоре открывает для себя также богатейший мир русской и западноевропейской литератур.

В Уральске Тукай формируется как поэт и журналист. В 1905 году он поступает в типографию наборщиком. Позже работает в редакциях газет и журналов «Фикер», «Эль-гаср-эль-джадид», «Уклар», где публикуются

его стихи, статьи и фельетоны. Его имя обретает известность не только в Уральске, но и в Казани, Оренбурге, Петербурге.

Осенью 1907 года Г.Тукай приезжает в Казань, здесь начинается наиболее плодотворный период в его жизни. Он знакомится с литературной молодежью, передовой интеллигенцией. Х.Ямашев, Г.Кулахметов, Ф.Амирхан, Г.Камал становятся близкими его друзьями. Тукай начинает публиковать свои произведения в редактируемой Ф.Амирханом газете «Аль-Ислах». Вместе с Г.Камалом выпускает сатирический журнал «Яшен». Позже начинает выходить журнал «Ялт-йолт» под редакцией А.Урманчеева. Г.Тукай отдаёт много сил журналу, здесь публикуется большинство его сатирических произведений.

Будучи в Казани, Г.Тукай много сил посвящает изучению народной литературы, её пропаганде, а также развитию литературы для детей. Подлинный расцвет поэзии поэта падает на казанский период. Г.Тукай участвует в литературных вечерах, концертах, лекциях, огромное внимание уделяет становлению татарского национального театра.

В 1911–1912 годах, несмотря на резкое ухудшение здоровья, Тукай отправляется в длительные поездки: весной 1911 года посещает Астрахань, в конце того же года едет в Заказанье, в деревню Училе, на родину своей матери, весной 1912 года совершает путешествие в Уфу, Петербург и Троицк.

Г.Тукай умер 15 (2) апреля 1913 года в Клячкинской больнице города Казани; похоронен на Ново-Татарском кладбище.

Универсальность мышления и сама личность поэта способствовали отображению в его творчестве многообразной картины жизни татарского народа, предопределили его первостепенное значение в татарской поэзии начала XX века.

Короткий, но яркий творческий и жизненный путь Тукая поражает воображение. С 1905 года – времени опубликования первых его произведений – до 1913 года – года безвременной кончины поэта – им созданы девять поэм, сотни стихотворений, десятки публицистических статей, большое число переводов на татарский язык. Тукаем заложены основы татарской реалистической критики.

Имя Тукая означает целую эпоху в духовном развитии татарского народа, в становлении его литературы, искусства, культуры в целом. Поэт навсегда остался в благодарной памяти народа.

Произведения Г.Тукая большими тиражами издаются на русском и многих других национальных языках страны. В целях популяризации творчества Тукая, увековечения его имени в 1958 году учреждена Государственная премия Республики Татарстан им. Г.Тукая; открыты Музей в с. Новый Кырлай, Дом-музей Тукаевых в деревне Кушлавыч Арского района, Литературный музей в Казани; ежегодно проводятся праздники поэзии в день рождения Г.Тукая. 26 апреля объявлен в Республике Татарстан Днём родного языка.

Татар халкының бөек шагыйре, әдәби тәнкыйтьче, публицист Габдулла Тукай (Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев) 1886 елның 26 апрелендә Казан губернасының (хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы) Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туа. Яшьли ятим калып, ятимлекнең бөтен ачысын татып үсә.

Кырлайда торганда Габдулла укырга йөри башлый. Кырлай тирәсе бөтен буачишмәләре, кара урманнары, уен-җырлары, йолалары белән Тукай-шагыйрьгә үз гомеренә җитәрлек рухи азык бирә.

1895 елда Габдулланы Уральск (Җаек) шәһәрендәге туганнарына җибәрәләр. Биредә ул «Мотыйгия» мәдрәсәсендә һәм параллель

рәвештә өчьеллык рус мәктәбендә дә укый. Мәдрәсәдә гарәп, фарсы, төрек телләрен бик яхшы үзләштерүе белән беррәттән, ул рус һәм Европа әдәбияты дөньясына да чума.

Уральск – Г.Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак канат ныгыткан урыны. 1905 елда ул типографиягә хәреф җыючы булып урнаша. Алга таба «Фикер», «Әл-гасрел-җәдит», «Уклар» газета-журнал редакцияләрендә эшли, күпләгән шигырь, мәкалә һәм фельетоннар белән чыгыш ясый.

1907 елның көзендә Г.Тукай Казанга кайта һәм әдәбият мохитенә чума. Ул үзенә тиң әдипләр, газета-журнал тирәсендәге кешеләр, алдынгы зыялылар белән таныша, Х.Ямашев, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан, Г.Камал белән дуслаша. Тукай Ф.Әмирхан җитәкчелегендә чыгарылган «Әл-Ислах» газетасына да актив язышa. Г.Камал белән «Яшен» исемле сатирик журнал чыгара. Соңрак «Ялт-йолт» журналында эшли һәм анда үзенең күпләгән сатирик әсәрләрен бастыра.

Г.Тукай Казанда балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнү, бастырып чыгару эшенә нигез сала. Тукай поэзиясенең чәчәк аткан вакыты – әлбәттә, Казан чоры.

Тукай әдәби кичәләрдә, концертлар, лекцияләр оештыруда актив катнаша. Ул татар милли театрының барлыкка килүенә дә зур игътибар бирә.

1911–1912 елларда шагыйрь, авыруының һаман көчәя баруына карамастан, Казаннан читкә озак сәяхәтләргә чыгып китә. 1911 елның язында ул Әстерханга барып чыга, шул ук елның көзендә Өчилегә кайтып, абзасы йортында кышны үткәрә. 1912 елның язында Уфада, Петербургта һәм Троицк якларында булып кайта.

Г.Тукай 1913 елның 15 (2) апрелендә Казанның Клячкин шифаханәсендә вафат була; Яңа Татар зиратында җирләнә.

Шагыйрьнең бөек талант иясе һәм киң мәгълүматлы шәхес булуы татар халкы тормышын бөтен тулылыгында гәүдәләндерү һәм XX йөз башы татар поэзиясен моңарчы күрелмәгән тизлек һәм сәнгати камиллек белән үстереп җибәрү өчен зур мөмкинлекләр ача.

Әдәбиятыбыз тарихында бай мирас калдырган Г.Тукайның эшчәнлеге гаҗәеп дәрәҗәдә күпкырлы, әһәмиятле. Ул – зур хезмәтләр тудырган шәхес. Кыска гына иҗат гомерендә – беренче шигыре басылган 1905 елдан 1913 елга кадәр – ул тугыз поэма, йөзләрчә шигырь, уннарча публицистик мәкалә яза, татар теленә И.А.Крылов мәсәлләрен, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Байрон, Гёте, Гейне шигырьләрен тәрҗемә итә. Тукай – татар реалистик тәнкыйтенә нигез салучы да.

Г.Тукай татар халкының сөекле шагыйренә әверелә, тормышы һәм иҗаты бөтен татар әдәбияты үсешенә бүген дә үзенең шифалы йогынтысын ясап тора. Аның әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Тукай иҗатын популярлаштыру, аның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә бик күп эш башкарыла: 1958 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге булдырыла, Арча районының Яңа Кырлай авылында Г.Тукай музей-комплексы, Арча районы Кушлавыч авылында Тукаевлар музей-йорты, Казанда Габдулла Тукай әдәби музее эшли, һәр елны Тукайның туган көнендә Шигырь бәйрәме үткәрелә. 26 апрель Татарстанда Туган тел көне дип игълан ителде.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Габдулла Тукай: библиогр.** күрсәткеч. 1956–1970 / [төз. Л.Хәйдәрова, Н.Әхмәтҗанова] = Габдулла Тукай: библиогр. указ. 1956–1970 / [сост. Л.Хайдарова, Н.Ахметзянова]. – Казан:

Казан ун-ты нәшр., 1974. – 116 б. – Текст татар, рус телләрендә.

**Габдулла Тукай:** библиографик күрсәткеч / төз. Р.Ф. Исламов. – Казан: «Мәгариф-Вакыт», 2016. – 477 б.

**Тукай Г.** Стихотворения, поэмы и сказки: [пер. с татар.] / [сост. В.Ганиев, Р.Бухараев; предисл. С.Хакима]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 415 с.

**Тукай Г.** Стихотворения и поэмы: [пер. с татар.]. – Л.: Сов. писатель, 1988. – 432 с.

**Тукай Г.** Избранная проза / [пер. с татар.; авт. предисл. М.Рафиков]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – 128 с.

**Тукай Г.** Избранное. – Казань: Магариф, 2008. – 223 с.

**Тукай Г.** (Тукаев Г.М.) Избранное: стихи и поэмы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 191 с.

**Тукай Г.** Избранное. – Казань: Магариф, 2006. – 239 с.

**Тукай Г.** Путеводная звезда: избранное. – Казань: Таглимат, 2006. – 198 с. – Текст парал.: на рус. и татар. яз.

**Тукай Г.** Последняя капля слезы: стихотворения / сост., автор предисловия Л.Шаех; перевод с татар.: А.Ахматовой, С.Ботвинника, В.Тушновой [и др.]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2016. – 383 с.: портр.

**Тукай Г.** Избранное: перевод с татар. / рук. проекта, сост. Л.Шаех; автор предисловия Р.Бухараев. – 2-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2023. – 215 с.: портр.

**Тукай Г.** Әсәрләр: алты томда: академик басма / ТР Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011–2016.
Т. 1: Шигъри әсәрләр (1904–1908) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М.Кадыйров, З.Г.Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш.Хисамов, З.З.Рәмиев]. – 2011. – 407 б.
Т. 2: Шигъри әсәрләр (1909–1913 / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р.Шәйхелисламов, Г.А.Хөснетдинова, Э.М.Галимҗанова, З.З.Рәмиев]. – 2011. – 384 б.
Т. 3: Мәкаләләр, фельетоннар, хикәяләр (1904–1906) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р.Шәйхелисламов]. – 2015. – 415 б.
Т. 4: Проза, публицистика (1907–1913) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г.Мөхәммәтшин]. – 2015. – 431 б.
Т. 5: Мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913) / төз., текст., иск. һәм аңлатмалар әзерләүчеләр: Г.Хөснетдинова, Г.Ханнанова. – 2016. – 415 б.: портр.
Т. 6: Г.Тукай төзегән җыентыклар, архив материаллары, документлар / төз., текст., иск. һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр, кереш сүз авт.: Э.Галимҗанова, Ф.Фәйзуллина. – 2016. – 471 б.: портр., рәс.

**Тукай Г.** Сайланма әсәрләр: 2 томда. – Казан: Татар кит. нәшр., 2006.
Т. 1: шигырьләр, поэмалар / [кереш сүз язучы Н.Хисамов]. – 2006. – 271 б.
Т. 2: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. – 2006. – 383 б.

**Тукай Г.** Сайланма әсәрләр /[мөх-р Р.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 703 б.: рәс. – Татар һәм рус телләрендә.

**Тукай Габдулла. Актык тамчы я**шь: шигырьләр / [төз. һәм кереш сүз авт. Л.Шәех]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 494 б.

**Тукай Г.** Сайланма әсәрләр / кереш мәкалә авт.: Р.Бохараев. – Казан: Татар. кит нәшр., 2021. – 215 б.

**Тукай Г.** Сагыныр вакытлар: балалар өчен шигырьләр, шигъри әкиятләр, автобиографик повесть. – Казан: Мәгариф, 2006. – 207 б.: рәс. б-н. – Текст парал.: татар һәм рус телләрендә.

**Тукай Г.** Бәхетле бала = Счастливый ребёнок: балалар өчен шигырьләр, поэмалар, автобиографик повесть, мәсәлләр. – Казан:

Татар кит. нәшр., 2011. – 215 б. – Татар һәм рус телләрендә.

**Тукай Г.** Су анасы: балалар өчен әкият-поэма = Su anasi: balalar өçen əkiyət-poema = Водяная: сказка-поэма для детей = The Water Maid: a fairy-tale in verse for children = Su Anasi: çocuklar için masal şiir / [рус теленә тәрҗ. Р.Бохараев; ингл. теленә тәрҗ. А.Шәмсетдинов; төрек теленә тәрҗ. Ф.Кутлу]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 31 [1] б.: рәс. б-н. – Текст татар, рус, инглиз, төрек телләрендә.

